ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

**«Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы таныклыгы һәм отставкадагы Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы таныклыгы турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы таныклыгы һәм отставкадагы Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы таныклыгы турында» 2001 елның 22 февралендәге 626 номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2001, № 1 – 2; 2007, № 12 (IV өлеш); 2013, № 6 (IV өлеш); 2015, № 11 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктта җөмлә башына «Вазыйфага өч елга сайланган» сүзләрен өстәргә;

2) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пункт өстәргә:
«$3^1$. Вазыйфага вәкаләтләр срогы чикләнми сайланган Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы таныклыгы үрнәген расларга ($3^1$ нче кушымта).»;

3) 1 нче кушымтаның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Вазыйфага өч елга сайланган Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы таныклыгы аның вәкаләтләр срогына бирелә, бу хакта Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы таныклыгында язып куела.
Вазыйфага вәкаләтләр срогы чикләнми сайланган Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы таныклыгында һәм отставкадагы Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы таныклыгында таныклыкның гамәлдә булуы тәмамланган срок күрсәтелми.»;

4) 2 нче кушымтада:

а) өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Судья таныклыгының эчке ягында сулда татар һәм рус телләрендә документның исеме (таныклык – удостоверение) һәм аның номеры, биләгән вазыйфа, суд участогының номеры, суд районының һәм республиканың исеме, фамилия, исем, атасы исеме (булган очракта) күрсәтелгән текст урнаштырыла. Мәсәлән:

Татарстан Республикасы<br>Кукмара суд районы буенча 2 нче суд участогы<br>җәмәгать судьясы<br>Хәбибуллина Венера Рөстәм кызы<br>Таныклык №

Удостоверение №<br>Мировой судья судебного участка № 2<br>по Кукморскому судебному району Республики Татарстан<br>Хабибуллина Венера Рустамовна»;

б) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Судья таныклыгының эчке ягында уңда Татарстан Республикасы җәмәгать судьясының 25х30 мм зурлыгында фотографиясе урнаштырыла. Вазыйфага өч елга сайланган Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы таныклыгында фотографиядән сулда судья таныклыгының гамәлдә булу срогы күрсәтелә, ул сайланган срокка туры килергә тиеш. Тиешле вазыйфага вәкаләтләр срогы чикләнми сайланган Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы таныклыгында срок күрсәтелми.»;

5) 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы<br>Дәүләт Советының<br>2001 елның 22 февралендәге<br>626 номерлы карарына<br>3 нче кушымта

**Вазыйфага өч елга сайланган**
**Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы таныклыгы**
**үрнәге**

<table>
<tr><td></td><td>Герб РФ Герб РТ<br>Россия Федерациясе<br>Татарстан Республикасы<br>Җәмәгать судьясы<br><br>Российская Федерация<br>Республика Татарстан<br>Мировой судья</td></tr>
</table>

<table>
<tr><td>Татарстан Республикасы<br>Кукмара суд районы буенча<br>2 нче суд участогы<br>җәмәгать судьясы<br><br>Хәбибуллина Венера<br>Рөстәм кызы<br><br>Таныклык №<br><br>Удостоверение №<br>Мировой судья судебного участка № 2 по Кукморскому судебному району Республики Татарстан<br><br>Хабибуллина Венера<br>Рустамовна</td><td>Таныклыкның<br>гамәлдә булу срогы<br>08.07.2024 кадәр<br><br>ФОТО<br>печать<br><br>Срок действия<br>удостоверения<br>до 08.07.2024<br><br>Татарстан Республикасы<br>Дәүләт Советы Рәисе<br><br>Председатель<br>Государственного Совета<br>Республики Татарстан Ф.Х. Мухаметшин</td></tr>
</table>

»;

6) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ нче кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасы
Дәүләт Советының
2001 елның 22 февралендәге
626 номерлы карарына
$3^1$ нче кушымта

**Вазыйфага вәкаләтләр срогы чикләнми сайланган Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы таныклыгы үрнәге**

| | |
|---|---|
| | Герб РФ Герб РТ<br>Россия Федерациясе<br>Татарстан Республикасы<br>Җәмәгать судьясы<br><br>Российская Федерация<br>Республика Татарстан<br>Мировой судья |

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы<br>Кукмара суд районы буенча<br>2 нче суд участогы<br>җәмәгать судьясы<br><br>**Хәбибуллина Венера**<br>**Рөстәм кызы**<br><br>Таныклык №<br><br>Удостоверение №<br>Мировой судья судебного участка № 2 по<br>Кукморскому судебному району<br>Республики Татарстан<br><br>**Хабибуллина Венера**<br>**Рустамовна** | ФОТО<br>печать<br><br>Татарстан Республикасы<br>Дәүләт Советы Рәисе<br><br>Председатель<br>Государственного Совета<br>Республики Татарстан Ф.Х. Мухаметшин |

»;

7) 4 нче кушымтаның өченче абзацына «атасының» сүзеннән соң «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә.

2. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларына әлеге карар үз көченә кергәнче бирелгән таныклыклар бирелгән сроклары тәмамланганчы гамәлдә була дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2021 елның 8 июле
№ 1045-VI ДС